| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.01.2020 г. Олы Подберезье ав. № 1

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең 2019-2029 елларга транспорт инфраструктурасын комплексłы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларынын транспорт инфраструктурасын комплексłы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын үстерүне тәэмин итү, аның иминлеге дәрәҗәсен күтәрү максатыннан, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплексłы үстерү программасына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 30 сентябрендәге 11 номерлы карары белән расланган «2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплексłы үстерү программасына үзгәрешләр кертү хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа паспортында 8 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 8 | Финанслау чыганаклары | Программа буенча финанслауның гомуми күләме муниципаль берәмлек бюджеты акчаларыннан 19 753,9 млн сум тәшкил итә. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Искәрмә: Финанслау күләме фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш |

муниципаль программага 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

2 нче таблица

| Чаралар исеме | Объектның урнашу урыны | Вакыты, период | Кирәкле финанслау |
|---|---|---|---|
| Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник документларындагы мәгълүматларны актуальләштерү, бүлеп бирелгән полосаларны билгеләү | Олы Подберезье ав., Кече Подберезье ав., Каргалы ав., Плетени ав., Сосновка ав. | 2020-2029 еллар | |
| Җирлек урамнарында һәм автомобиль юлларында барлык инженерлык корылмаларының техник торышын бәяләп инвентарьлаштыру | Олы Подберезье ав., Кече Подберезье ав., Каргалы ав., Плетени ав., Сосновка ав. | 2020 | 7,89 |
| | | 2021 | 7,89 |
| | | 2022 | 7,89 |
| | | 2023 | 7,89 |
| | | 2024 | 7,89 |
| | | 2025-2029 | 39,45 |
| Юллар өслеген үзгәртүне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлегенә үзгәрешләр кертү | Олы Подберезье ав., Кече Подберезье ав., Каргалы ав., Плетени ав., Сосновка ав. | 2020-2029 еллар | |
| Территорияләрне планлаштыру буенча документацияне эшләү белән бергә юл хәрәкәте иминлеге буенча комплекслы чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру | Олы Подберезье ав., Кече Подберезье ав., Каргалы ав., Плетени ав., Сосновка ав. | 2020-2029 еллар | |
| Торак пунктларның урамнарына реконструкция, ремонт ясау, каты өслек урнаштыру | Олы Подберезье ав., Кече Подберезье ав., Каргалы ав., Плетени ав., Сосновка ав. | 2020 | 1 967,5 |
| | | 2021 | 1 967,5 |
| | | 2022 | 1 967,5 |
| | | 2023 | 1 967,5 |
| | | 2024 | 1 967,5 |
| | | 2025-2029 | 9 837,5 |
| БАРЫСЫ: | | | 19 753,9 |

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы: Ф.А. Чекмарев